ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ с. Верхний Услон КАРАР ______________

Агачларны һәм куакларны кисүгә, сирәкләү яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Югары Ослан муниципаль районы муниципаль хакимият органнарының физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын арттыру максатларында һәм Россия Федерациясенең 25.10.2001 ел, №136-ФЗ Җир кодексы, 04.12.2006 ел, № 200 – ФЗ Россия Федерациясе Урман кодексы, «Әйләнә-тирәлекне саклау турында» 10.01.2002 ел, №7-ФЗ Федераль закон белән расланган Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен игътибарга алып, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставы белән, Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Агачларны һәм куакларны кисүгә, сирәкләү яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгына әлеге карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын үтәүне тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Социаль-икътисадый үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хәкимҗанов

Әзерләде һәм бастырды:
А.Д.Сагдеева
2 экз.